Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы “Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе”
муниципаль берәмлеге Тихоновка авылы
гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

28 ноябрь 2022 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2022 елның 27 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта, 2022 елның 27 ноябрендә 10 сәгать 30 минутта, 2022 елның 27 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта, 2022 елның 27 ноябрендә 13 сәгать 30 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге «Сез 2023 елда Тихоновка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (1 төркем инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның толларыннан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, мобилизация буенча чакырылган гаиләләрдән тыш) 400 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: юлларны, балалар мәйданчыкларын, урам утларын норматив хәлгә китерү, тротуарларны салу һәм норматив хәлгә китерү, трактор сатып алу, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләүгә ризамы?” соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 1428 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 740 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 390 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 350 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы “Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге Тихоновка авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. “Сез 2023 елда Тихоновка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (1 төркем инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның толларыннан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, мобилизация буенча чакырылган гаиләләрдән тыш) 400 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: юлларны, балалар мәйданчыкларын, урам утларын норматив хәлгә китерү, тротуарларны салу һәм норматив хәлгә китерү, трактор сатып алу, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү?” турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Тихоновка авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат

стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Мактама бистә башлыгы Р.А. Бәдретдинов